КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 август г.Казань №717

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби припасларның, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби припасларның, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби припасларның, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 ел, 15 ноябрь, 832 нче; 2002 ел, 25 октябрь, 625 нче; 2003 ел, 4 апрель, 179 нчы; 2004 ел, 17 май, 239 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 724 нче; 2010 ел, 17 август, 661 нче; 2012 ел, 25 сентябрь, 800 нче;

2016 ел, 31 март, 192 нче һәм 2016 ел, 13 сентябрь, 638 нче, 2019 ел, 1 апрель, 255 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби припасларның, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «аларда сакланыла торган, шул исәптән тиешле рөхсәтеннән башка да, яки табылган корал» сүзләрен «аларда тиешле рөхсәтеннән башка сакланыла торган яки табылган корал» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Акчалата бүләк түбәндәге күләмдә түләнә:

хәрби утлы корал, хезмәт утлы коралы өчен 15 000 сум;

киселгән көпшәле гражданнар утлы коралы өчен 10 000 сум;

запалы гранаталар, миналар, снарядлар, шартлаткыч җайланма (аңа шартлаткыч матдә һәм шартлату чарасы керә) өчен 5 000 сум;

шома көпшәле гражданнар утлы коралы өчен 3000 сум;

кулдан ясалган яки үзгәртеп ясалган утлы корал өчен 3000 сум;

пневматик (3 Дж артык), газлы корал һәм зыяны чикләнгән утлы корал өчен 2000 сум;

шартлату чаралары (детонаторлар, шартлаткычлар, ут үткәргеч шнур һ. б.) өчен 500 сум;

утлы коралның төп өлешләре өчен 500 сум;

шартлаткыч матдәләр өчен (тротил, пластид, аммонит, гексоген һәм башка сәнәгый җитештерелгән) 50 сум (1 грамм өчен);

киселгән көпшәле утлы коралга патроннар өчен 30 сум (1 берәмлек өчен);

шома көпшәле утлы коралга патроннар өчен 20 сум (1 берәмлек өчен).

Законсыз сакланылучы корал, хәрби припаслар, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр турында дөрес мәгълүмат биргән өчен әлеге пункт белән корал, хәрби припаслар, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрнең төгәл төре өчен билгеләнгән сумманың 50 проценты күләмендә акчалата түләү түләнә.

Теркәлгән коралны ирекле тапшырган өчен хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы бәяләмәсе нигезендә әлеге пунктта билгеләнгән сумманың 50 проценты күләмендә стимуллаштыручы акчалата түләү түләнергә мөмкин.»;

6 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«акчалата түләүләрне (субсидия һәм пенсия счетларыннан тыш) күчерү өчен акчалата түләү алучы зат өчен ачылган счет реквизитлары»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, коралны ирекле тапшырган өчен түләү (түләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен бирелә торган документларны кабул итү һәм алар белән эшләү тәртибен муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнары аша (шәһәр округларында – башкарма комитетларның территориаль органнары аша) мөстәкыйль расларга хокуклы.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Коралны ирекле тапшырган өчен акчалата түләүне гамәлгә ашыру яки түләүдән баш тарту һәм акчалата бүләк күләмен билгеләү хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы карары (аның каршындагы махсус төзелгән эшче комиссия) нигезендә башкарыла.»;

8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы (аның каршында махсус төзелгән эшче комиссия) карары әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән тәртиптә кергән документлар нигезендә рәсмиләштерелә.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы ай саен хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы (аның каршында махсус төзелгән эшче комиссия) утырышында бүләкләү турындагы материалларны карауны тәэмин итү һәм хисаптан соң килүче айның 10 числосына кадәр, бүләкләү күләмен, акчалата бүләк алучының паспорт мәгълүматларын, салым түләүченең идентификация номерын, салым түләүченең акча күчерү өчен счет реквизитларын (субсидия һәм пенсия счетларыннан тыш) күрсәтеп һәм хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы (яисә махсус төзелгән эшче комиссия) карарларының төп нөсхәләрен һәм әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар күчермәләрен теркәп, түләүләрне гамәлгә ашыру өчен аны «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә җибәрә.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Коралны ирекле тапшырган гражданнарга акчалата түләү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан акча күчерүне гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 пунктлар өстәргә:

«12. »Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе вәкаләтләр бирү турындагы килешү нигезендә гражданнарга түләүләрне гамәлгә ашыруны турыдан-туры башкаручы булып тора.

13. »Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе салым түләүчедән исәпләү, тотып калу һәм физик затларның керемнәренә салымны түләү өлешендә бюджетка күчерү буенча гамәлдәге законнар нигезендә салым агенты булып тора.

Ел саен, финанс елы тәмамланганнан соң, салым инспекциясенә 2-НДФЛ формасы буенча түләүләр турында белешмәләр бирә һәм түләү алучының язмача гаризасы буенча аңа 2-НДФЛ формасы буенча белешмә бирә.».

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин